**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

«01» ноябрь 2023 ел № 37/2

# КАРАР

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 26 сентябрендәге 10/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 26 сентябрендәге 10/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге (пункт, абзац) өстәргә:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарын физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә, 2023 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Салым ташламасы түбәндәге салым салу объектларына карата бирелә: фатирлар, фатир өлешләре, бүлмә, торак йорт, торак йорт өлешләре. Салым ташламасы салым түләүчеләргә салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында, районның рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң бер ай узгач үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Д. М. Габделхаева